КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 30 декабрь г.Казань № 1238

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 елга Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау системасының медицина оешмалары тарафыннан донорлар канын һәм аның компонентларын хәзерләү, саклау, транспортта күчерү һәм аның куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча дәүләт эшен башкаруга норматив чыгымнарны раслау турында» 2018 ел, 19 сентябрь, 797 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 елга Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау системасының медицина оешмалары тарафыннан донорлар канын һәм аның компонентларын хәзерләү, саклау, транспортта күчерү һәм аның куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча дәүләт эшен башкаруга норматив чыгымнарны раслау турында» 2018 ел, 19 сентябрь, 797 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 11 март, 177 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау системасының донорлар канын һәм аның компонентларын хәзерләү, саклау, транспортта күчерү һәм аның куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча дәүләт эшен башкаручы медицина оешмалары норматив чыгымнарына карата индивидуаль коэффициентларның «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе» дигән юлында «0,51929» саннарын «0,51941» саннарына алыштырырга;

әлеге карар белән расланган Донорлар канын һәм аның компонентларын хәзерләү, саклау, транспортта күчерү һәм аның куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау системасының медицина оешмалары башкара торган дәүләт эше күләмнәрендә:

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе» бүлегендә:

«кан донорларыннан компонентларга аертылмаган донорлар каны» юлының 5 графасындагы «1 600,0» саннарын «2 152,9» саннарына алыштырырга;

«автоматик аферез ысулы белән компонентларга аертылмаган донорлар каны (плазмоферез ысулы белән яңа туңдырылган плазма хәзерләү өчен)» юлының 5 графасындагы «1 920,5» саннарын «2 668,1» саннарына алыштырырга;

«тромбоцитоферез ысулы белән компонентларга аертылмаган донорлар каны (плазмоферез ысулы белән яңа туңдырылган плазма хәзерләү өчен)» юлының 5 графасындагы «165,2» саннарын «1 281,0» саннарына алыштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин